Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы
Юлсубино авыл җирлеге составына керүче Юлсубино авылы торак пунктында

**ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

2021 елның 29 ноябре № 2

“Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” Федераль законның 25.1, 56 маддәләре, Татарстан Республикасының ”Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” Законының 35 маддәсе нигезендә, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Юлсубино авыл җирлеге составына керүче Юлсубино авылы торак пунктында гражданнар җыены **КАРАР БИРӘ**:

1. 2022елда Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль Юлсубино авыл җирлеге составына керүче Юлсубино авылы торак пунктында тору урыны буенча теркәлгән сайлау хокукына ия булган һәр кешесеннән, уку йортларына йөреп ,көндезге бүлектә укучы студентлардан гайре 600 сум күләмендә үзара салым акчасы кертергә.
2. Тупланган акчаларны түбәндәгеләргә юнәлтергә:

1.Юлсубино авыл торак пунктында урамнарны яктыртуга техник хезмәт күрсәтү .

2. Юлсубино авыл торак пунктында урам юлларын өлешчә ремонтлау.

3. Юлсубино авыл торак пунктында су үткәргечләргә ремонт һәм техник хезмәт күрсәтү

4. Юлсубино авыл торак пунктында урамнарны кышкы чорда кардан чистарту

5. Юлсубино авыл торак пункында физкультура-сәламәтләндерү һәм спорт чаралары аша халыкның ялын оештыру

6. Юлсубино авыл торак пунктында чишмә төзекләндерү

7. Һәйкәлне төзекләндерү һәм Бөек Ватан сугышында катнашучыларга мемориаль такта ясау.

8. Юлсубино т. п. контейнерлар сатып алу һәм контейнер мәйданчыгы төзү.

3. Гражданнар җыены нәтиҗәләрен Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль Юлсубино авыл җирлегенең түбәндәге адреслар буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендларында: Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе районы, Юлсубино авылы, Татарстан урамы, 56а йорт; Ямаш авылы,Х.Такташ урамы, 3в йорт; һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”ында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

4. Карарны Татарстан Республикасы үзидарәлек хокукый норматив актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Юлсубино авыл җирлеге башлыгы Х.Х.Гатиятов